РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.04.2021 № 421-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 3 сентябрендәге 1029-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү максатыннан, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Саба муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр төзү турында” 2019 елның 3 сентябрендәге 1029-п номерлы карары белән расланган, Саба муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Саба муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр исемлеген яңа редакциядә, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

**2.** Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Саба муниципаль районы
гражданнар оборонасы Җитәкчесе –
Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе – М.Р. Ишниязов

Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 14 апрелендәге
421-п номерлы карарына
1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә төзелгән гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү буенча территориаль штаттан тыш формированиеләр исемлеге

| № пп | ГОШТФ атамасы | Базасында ГОШТФ төзелә торган оешма (килешү буенча) | ГОШТФнең шәхси составы саны (кеше) | ГОШТФ структурасы | | | ГОШТФ билгеләнеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **Состав (постлар, төркемнәр, звенолар, командалар)** | **ГОШТФ структурасы составына керүче оешмалар** (килешү буенча) | **Составта бүлеп бирелә торган көчләр һәм чаралар** (килешү буенча) | |
| Территориаль формированиеләр | | | | | | | |
| 1 | Туклануның, азык-төлек (әйбер) белән тәэмин итүнең күчмә пунктлары | Саба районы кулланучылар берлеге | 15 | Туклану күчмә пункты | «Аш-су» КК | «Газель» машинасы - 2 бер. "Ларгус" машинасы-1 бер. Тагылма-1 бер. Кыр кухнясы Кп-125-1 бер. | Авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үтәү барышында ГОШТФнең шәхси составын һәм зарарлану учагында зыян күргән халыкны кайнар аш белән тәэмин итү |
| | | | 6 | Азык-төлек белән тәэмин итүнең күчмә пункты | «Аш-су» КК | «Газель» машинасы - 1 бер. Тагылма-1 бер. | Зарарлану учагында зыян күргән халыкны азык-төлек белән тәэмин итү |
| | | | 12 | Әйберләр белән тәэмин итүнең күчмә пункты | «Икмәк» ҖЧҖ | “Газель” машинасы-2 бер. Тагылма-1 бер. | Зарарлану учагында зыян күргән халыкны беренче кирәк-яраклар, кием-салым һ. б. белән тәэмин итү |